**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КРАСНОСЕЛЬСКИЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422700, Татарстан Республикасы, Биектау районы, Биектау тимер юл станциясе поселогы, Совет ур., 13

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ КРАСНОСЕЛЬСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422700, Республика Татарстан, Высокогорский район, п. ж/д ст. Высокая Гора, ул. Советская, 13

тел./факс 8(84365) 2-35-82, e-mail: Ksel.Vsg@tatar.ru

**КАРАР**
**19 ноябрь 2019 ел**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№ 33**

**Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз һәм сукбай хайваннарны тоту һәм карап торуны оештыру Тәртибен раслау турында**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон, “Хайваннар белән җаваплы эш итү һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында”, 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы Федераль законнар нигезендә, Казаклар авыл җирлеге территориясендә санитария - эпидемиология һәм ветеринария иминлеген тәэмин итү максатларында, Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставы белән эш йөртеп, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Теркәлгән Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз һәм сукбай хайваннарны тоту һәм карап торуны оештыру Тәртибен расларга.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” Интернет мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштырып бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар бастырып чыгарган (халыкка җиткерелгән) вакыттан үз көченә керә.
4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Красносельский авыл җирлеге
башкарма комитеты җитәкчесе И.З.Газизов

Кушымта

РАСЛАНГАН

ТР Биектау муниципаль районы
Красносельский авыл җирлеге
Башкарма комитеты карары белән
19.11.2019 № 33

**Биектау муниципаль районы Красносельский авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз һәм сукбай хайваннарны тоту һәм карап торуны оештыру**
**ТӘРТИБЕ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Тәртип "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында", 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон һәм "Халыкның санитар-эпидемиологик иминлеге турында", 1999 елның 30 мартындагы 52-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләре нигезендә эшләнгән.

1.2. Әлеге Тәртип авыл җирлеге территориясенең тиешле санитар торышын тәэмин итүне, халыкның хуҗасыз хайваннарның начар тәэсиреннән куркынычсызлыгын, хуҗасыз хайваннарның санын җайга салуның гуманлы методларын куллануны регламентлый, авыл җирлеге территориясендә хуҗасыз хайваннарны тоту, карап тору, йокыга талдыру һәм утильләштерүне оештыруны һәм тәэмин итүне билгели.

1.3. Әлеге Тәртиптә кулланыла торган төп төшенчәләр һәм аларның билгеләмәләре:

1) хайванның хуҗасы (алга таба шулай ук - хуҗа) – милек хокукында яки башка законлы нигездә хайваны булган физик зат яки юридик зат;

2) хуҗасыз калган хайваннар белән эш итү буенча эшчәнлек – хуҗасыз калган хайваннарны тоту, аларны кара тору (шул исәптә дәвалау, вакцинацияләү, стерилизацияләү), аларның элеккеге яшәгән урыннарына кайтару һәм Федераль законнар белән күздә тотылган башка эшчәнлек;

3) ирексез шартларда карап тотыла яки кулланыла торган кыргый хайваннар (алга таба шулай ук - иректә булмаган кыргый хайваннар) – яшәү мохитеннән алынган (шул исәптән Россия Федерациясе территориясенә чит дәүләтләрдән кертелгән) кыргый хайваннар, әлеге хайваннарның токымнары (шул исәптән гибридлар);

4) йорт хайваннары – хуҗа-физик зат карамагында вакытлыча яки даими күзәтчелектә булган хайваннар (карап торылырга тиеш булмаган хайваннар исемлегенә кергщн хайваннардан кала), аларны тоту урыннары булып зоопарклар, зообакчалар, цирклар, зоотеатрлар, дельфинарийлар, оеанариумнар тормый;

5) Хайванга карата рәхимсез мөнәсәбәт – хайван белән аның үлеменә китергән яки китерергә, җәрәхәт салырга яки сәламәтлегенә башка зыян китерергә мөмкин булган мөнәсәбәт (хайванны җәфалауны кретеп, шул исәптән ач тоту, су бирмәү, кыйнаулар, башка гамәлләр), әлеге федераль закон, башка федераль законнар һәм Россия Федерациясе норматив хокукый актлары белән билгеләнгән тәртиптә

хайваннарны карап тоту таләпләрен бозу (шул исәптән хуҗаның хайванны караудан баш тартуы), хайванның сәламәтлегенә зыян китерү, яисә хайванның хуҗасы тарафыннан аның тормышы һәм сәламәтлегенә куркыныч янаган вакытта мөмкинлек булып та булышмавы;

6) хуҗасыз калган хайван – хуҗасы булмаган яки хаҗасы билгеле булмаган хайван;

7) хайванны мәдәни-күңел ачу максатларында файдалану – мәдәният, ял итү һәм күңел ачу эшчәнлеген тормышка ашырганда хайваннарны куллану (шул исәптән зоопаркларда, зообакчаларда, циркларда, зоотеатрларда, дельфинарийларда, оеанариумнарда), хайваннар күргәзмәләрендә, япорт ярышларында, реклама төшерү процессында, кинематография әсәрләрен булдырган вакытта, фото һәм видео продукциясе эшләгәндә, телевидениедә, агарту эшчәнлегендә, күрсәтү максатларында (шул исәптән ваклап сату урыннарында, җәмәгать туклануы хезмәте күрсәтү урыннарында);

8) хайванны карап тоту урыны – тәүлекнең күпчелек вакытында хайван тора торган хайван хуҗасы тарафыннан кулланыла торган бина, корылма яки территория;

9) хайваннар белән мөгаләмә – хайваннарны карап тоту, куллану, хуҗасыз хайваннар белән мөгаләмә буенча эшчәнлекне тормышка ашыру һәм әлеге федераль закон белән күздә тотылган башка эшчәнлек, шулай ук аларның тормышына һәм сәламәтлегенә тәэсир итүче хайваннарга карата башка төрле гамәлләр кылу;

10) потенциаль куркыныч хайваннар – аерым бер токымлы этләр, аларның гибридлары һәм кешенең тормышына һәм сәламәтлегенә потенциаль куркыныч тудыра торган һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте белән расланган потенциаль куркыныч этләр исемлегенә кертелгән башка этләр;

11) хезмәттә кулланылучы хайваннар – ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү, җәмәгать тәртибен саклау һәм җәмәгать иминлеген тәэмин итү, хәрби, мөһим дәүләт һәм башка махсус объектларны саклау, халыкның тормыш иминлеген тәэмин итүче, транспорт эшен, коммуникацияләрне һәм элемтәне, энергетика объектларын һәм башка объектларны саклау максатларында, һәм Россия Федерациясе законнары белән билгеләнгән башка максатларда махсус әзерләнгән һәм кулланыла торган хайваннар;

12) ирексез шартлар – хайваннар өчен махсус җиһазландырылмаган урыннарда ирекле йөри алу мөмкинлеге булмаган һәм хайваннарның тормыш белән тәэмин итүе тулаем кешедән торган .ясалма тудырылган яшәү шартлары;

- хуҗасыз хайваннарны тотуны тәэмин итү – хуҗасыз хайваннарны тоту, аларны карап тоту урыннарында тоту, хуҗаларына таләпләре буенча кайтару, йоклату һәм хайваннарны утильләштерү.

## 2. Сукбай һәм күзәтүчесез хайваннарны тоту шартлары

2.1. Сукбай этләрне һәм мәчеләрне тоту кеше һәм хайваннар өчен уртак булган авыруларны кисәтү һәм тарату, авыл җирлеге территориясендә халыкның тәртибен һәм тынычлыгын тәэмин итү максатларында башкарыла.

2.2. Сукбай һәм хуҗасыз хайваннарны тоту һәм ташу хайваннар белән гуманлы мөнәсәбәт һәм иҗтимагый әхлак нормаларын үтәү принципларына нигезләнеп башкарыла. Хуҗасыз этләрне һәм мәчеләрне тоту сукбай этләрне һәм мәчеләрне, этләрне һәм этләрне тоту вакытында имгәнми торган махсус техник җайланмаларны йөртү өчен махсус җиһазландырылган транспорт чаралары ярдәмендә башкарыла.

2.3. Тоту телдән һәм язмача гаризалар нигезендә генә башкарыла. Тоту өчен кергән барлык гаризалар, шулай ук бригадаларның урынга чыгуы катгый хисап документы булган махсус журналда мәҗбүри рәвештә теркәлергә тиеш.

2.4. Барлык сукбай һәм хуҗасыз хайваннар тотылырга тиеш. Беренче чиратта кешеләргә һәм башка хайваннарга, авыру куркынычы булган, шулай ук түбәндәге урыннарда булган хайваннар тотылырга тиеш:

мәктәпкәчә балалар учреждениеләре, мәктәпләр территорияләрендә;

сәламәтлек саклау учреждениеләре территорияләрендә;

мәдәният учреждениеләре территорияләрендә;

күпфатирлы торак йортлар территорияләрендә;

халык күпләп су коену урыннары территорияләрендә;

урам-юл челтәрендә һәм транспорт һәм (яки) җәяүлеләр хәрәкәте өчен куркыныч тудырган урыннарда;

шәхси торак төзелеше урамнары территорияләрендә

2.5. Подъездларда, подвалларда, биналарда хайваннарны тоту идарә оешмалары хезмәткәрләре яки предприятие, оешма, учреждение вәкилләрен алып бару шарты белән башкарыла.

2.6. Тыела:

хайваннарны яки аларның тормышы һәм сәламәтлеге өчен куркыныч булган техник җайланмалар һәм препаратлар кулланып, тоту ысуллары;

хуҗасыз хайваннарны тотканда хайваннарны (чыбык элмәкләре, ыргаклар һәм башкалар) җәрәхәтли торган җайланмалар куллану;

хуҗасыз этләрне һәм мәчеләрне утлы коралдан, гражданнарның үз-үзеңне саклау һәм ашыгыч саклану очракларыннан тыш атып үтерү;

аларны транспортлаганда һәм вакытлыча тотканда сукбай һәм хуҗасыз хайваннар белән рәхимсез мөгаләмә;

тотылган хайваннарны үзеңә калдырырга, аларны шәхси затларга яки башка оешмаларга сатарга һәм тапшырырга;

милекчеләр рөхсәтеннән яки суд карарыннан башка фатирлардан һәм шәхси йортлардан хайваннарны тартып алу. Йорт хайванын хуҗасыннан мәҗбүри рәвештә тартып алу, гамәлдәге законнарда каралган очраклардан тыш, рөхсәт ителми;

кибет, даруханәләр, коммуналь хезмәт күрсәтү предприятиеләре һәм башкалар янында этләрне тотарга;

биологик калдыкларны ташларга һәм күмәргә.

## 3. Хуҗасыз хайваннарны тотуны оештыру

3.1. Хуҗасыз хайваннарны тоту һәм әлеге эшчәнлек төренә лицензиясе булган

хайваннар яки физик затлар белән эшләү буенча гамәлдәге законнар һәм әлеге Тәртип нигезендә хуҗасыз хайваннарны тоту буенча хезмәт күрсәтүгә муниципаль контракт (шартнамә) нигезендә махсуслаштырылган оешма бригадасы башкара.

3.2. Авыл җирлеге чикләрендә хуҗасыз хайваннарны тоту эшен оештыру җирлек администрациясе тарафыннан гамәлдәге законнарда билгеләнгән тәртиптә хуҗасыз хайваннарны тоту буенча оешма белән килешүләр төзү юлы белән башкарыла.

3.3. Җирлек администрациясе хуҗасыз хайваннарны тоту эшчәнлеге буенча бюджет чыгымнарын планлаштыра, контрольдә тота, гамәлдәге законнар нигезендә функцияләр башкара;

3.4. Тотуны оештыру буенча оешма хезмәткәрләргә инструктаж үткәрә һәм аларга, гражданнарга беренче таләп буенча куела торган, хуҗасыз этләрне һәм мәчеләрне тоту хокукына таныклыклар бирә.

3.5. Хуҗасыз хайваннарны тоту җирлек администрациясе белән килешенгән график нигезендә башкарыла.

Кеше һәм хайваннар өчен уртак аеруча куркыныч йогышлы авырулар барлыкка килү һәм күпләп таралу куркынычы булган очракта, хуҗасыз йорт хайваннарын тоту турында карар дәүләт ветеринария һәм (яки) дәүләт санитария-эпидемиология хезмәтләре мәгълүматлары нигезендә кичекмәстән кабул ителә.

3.6. Тоту белән шөгыльләнүче оешма 3 тәүлек дәвамында хуҗасыз хайваннарны ашату һәм тоту белән шөгыльләнә.

3.7. Хуҗалары булырга тиешле билгеләре булган йорт хайваннардан аерым бер урында алты ай дәвамында тотылырга тиеш.

Мондый хайваннарны тоту турында аулаучы оешма, хайван тотылган көннән өч көннән дә соңга калмыйча бу турыда полициягә яки җирлек администрациясенә гариза бирергә бурычлы.

3.8. Хуҗасыз хайваннар турында мәгълүмат һәркемгә ачык һәм аңлаешлы булып тора. Кызыксынган барлык гражданнар һәм юридик затлар оешма күрсәткән телефон аша тотылган хайваннар турында кирәкле мәгълүмат алу өчен оешмага мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3.9. Хайванның хуҗасы билгеле хайванны тотуга һәм карап тоту буенча махсуслаштырылган оешма чыгымнарын түләргә тиеш.

Чыгымнарны каплау махсуслаштырылган оешманың исәп-хисап счетына акча күчерү юлы белән башкарыла.

3.10. Йорт хайваннары хуҗаларының мөрәҗәгате булмаган очракта, соңгылары кызыксынган оешмаларга яки гражданнарга аларның гаризалары нигезендә тапшырылырга мөмкин.

3.11. Хуҗасына яки кызыксынган оешмаларга, гражданнарга тапшырылмаган тотылган йорт хайванннары агулап үтерелергә тиешле.

3.12. Тотылган йорт хайваннарын тоту вакытыннан алып, 8 сәгатьтән артык вакыт эчендә, махсус җиһазландырылган транспорт чараларында тоту тыела.

3.13. Кеше һәм башка хайваннарны тешләгән караучысыз хайваннар тотылырга яки иммобилизацияләнергә тиеш.

## 4. Финанс белән тәэмин итү һәм чараларны үтәү тәртибе

4.1. Җирлек территориясендә хуҗасыз хайваннарны тотуны оештыру һәм тәэмин итү буенча шартлар тудыру кысаларында башкарыла торган чыгымнар җирле бюджет акчалары хисабына финанслана.

4.2. Җирлек территориясендә хуҗасыз хайваннарны тоту белән тәэмин иткәндә, эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү төзелгән контрактлар, шартнамәләр шартлары нигезендә финанслана.

## 5. Хисаплылык

5.1. Башкаручы башкарылган эшләр турында хисапны муниципаль контракт һәм әлеге Тәртип нигезендә бирә.